**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__________________ ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы буенча
2022/2023 елгы ягу чорына әзерлек турында

Актаныш муниципаль районында 2022/2023 елгы ягу чорына үз вакытында әзерләнү һәм аны вакытында уздыру максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022/2023 елгы ягу чорына әзерлек буенча район штабының кушымтада бирелгән составын, (кушымта нигезендә) расларга.

2. Авыл җирлекләре башлыкларына, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә:

2022 елның 20 июненә кадәр, 2021/2022 елның көзге-кышкы чорында барлыкка килгән авария хәлләрен анализлауны исәпкә алып, 2022/2023 елның ягу чорына предприятиеләр һәм учреждениеләрне әзерләү буенча чаралар планын эшләргә, 2022/2023 елның ягып җылыту чорына әзерлекне бәяләү комиссиясен билгеләргә;

2022 елның 1 сентябренә кадәр, Актаныш муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре һәм учреждениеләре объектларын 2021/2022 елгы ягу чорына әзерләү эшләрен тәгәлләргә;

2022 елның 1 сентябренә кадәр тормыш тәэмин итү системаларында мөмкин булган аварияләрне оператив бетерү һәм хокук бозуларны бетерү өчен җиһазлар, материаллар һәм запас частьләр резервын формалаштырырга;

2022 елның 1 сентябренә кадәр энергия белән тәэмин итүче оешмаларның 2022/2023 елның ягу чорында эшләүгә әзерлеге паспортын рәсмиләштерергә;

бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларын исәпкә алып, электр, җылылык энергиясен һәм табигый газны агымдагы кулланугa түләүнең үз вакытында һәм тулылыгын тәэмин итәргә;

ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычларны тәэмин итүчеләр белән килештереп, 2022/2023 елның ягу чоры башланганчы каплау чараларын күрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына кушымта
«___»__________2022 ел, №___

2022/2023 ЕЛГЫ ҖЫЛЫТУ СЕЗОНЫНА ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА
РАЙОН ШТАБЫ СОСТАВЫ

Ильясов Р.А. - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - штаб башлыгы;
Гарипов Р.И. - штаб башлыгы урынбасары - инфраструктур үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;

Штаб әгъзалары:

Кустова Р. З - «Коммунсервис-Актаныш» ҖЧҖ директоры;
Нәгыймов Д.М. - «Теплосервис» ҖЧҖ директоры;
Шакиров М.М. «Сетевая компания» ААҖ Актаныш районы электр челтәре башлыгы;
Шакирова Р. М. - «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
Латыйпов Н.Н. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы;*
Хәев А. Р. «Актаныш РҮХ» ДАССУ баш табибы;
Хузин И.Т. - Актаныш авыл башкарма комитеты җитәкчесе *
Әмирҗанов Р.М «Әлмәтгаз»эксплуатация-җитештерү идарәсенең район газ хезмәте Башлыгы;
Шәрифьянов И.И. - 103 нче янгын сүндерү бүлеге башлыгы;
Хуҗахметова Г.Ф. - Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы;
Вәлиев Л.А. яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлек башлыгы;
Вафин Р.Ш. - Гомуми сәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелегенең Кама аръягы бүлеге башлыгы;
Идрисова Р.Р. Гомуми сәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелеге Кама аръягы бүлегенең баш дәүләт инспекторы;
Әхмәдиев Р.Р. гомумсәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелеге Кама аръягы бүлегенең өлкән дәүләт инспекторы;

*Башкарма комитет җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган затлар килешү буенча штаб составына кертелә.